РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная, д.25, с. Куралово,
422581

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.03.2019 с. Куралово 07

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге торак пунктларының территорияләрен санитар-экологик чистарту буенча икеайлык үткәрү турында**

Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге торак пунктларының территорияләрен төзекләндерү һәм санитар чистарту эшләрен оештыру һәм халыкның экологик иминлегенә җавап бирерлек хәлгә китерү өчен эшләр башкаруны оештыру өчен,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Куралово авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм санитар-экологик чистарту икеайлыгын игълан итәргә (алга таба – икеайлык).

2. Куралово авыл җирлеген төзекләндерү комитеты составын 2019 елга расларга. (1нче кушымта)

3. 2019 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Куралово авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү буенча чаралар планын расларга. (2 нче кушымта).

4. Куралово авыл җирлеге территориясендә урнашкан предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләренә, милек формасына карамастан, якын-тирә

территорияләрне санитар чистарту эшен оештырырга, икеайлык кысаларында оештырылган полигонга һәм чүплеккә каты көнкүреш калдыклары чыгару өчен йөк транспорты бүлеп бирергә тәкъдим итәргә. Урыннарда агачлар һәм куаклар утырту, биналарның фасадларын, балалар мәйданчыкларын ремонтлау эшен оештырырга.

5. Нинди хокукка карамастан, авыл җирлеге территориясендә күчемсез милек булган гражданнарга йорт яны территорияләрен санитар чистарту буенча эш үткәрергә тәкъдим итәргә.

6 Әлеге карарны Куралово авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә. Югары Ослан муниципаль районының мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Куралово авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе:** **Т.Ю.Тимиряева**

Башкарма комитеты җитәкчесенең
28 март 2019 ел №7 карарына
1 нче кушымта

**Куралово авыл җирлеген төзекләндерү комитеты составы**

1. Квашнева Венера Александровна – Куралово авыл җирлеге Башлыгы вазыйфаларын башкаручы
2. Тимиряева Татьяна Юрьевна- Куралово авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе
3. Баринова Ирина Владимировна- МБДОУ «Куралово балалар бакчасы» мөдире
4. Дряхлова Любовь Борисовна – авыл мәдәният йорты китапханәчесе
5. Куркова Светлана Владимировна – Куралово мәдәният йорты мөдире
6. Баканов Петр Александрович – Куралово авыл җирлеге депутаты, «Таткрахмалпатока» АҖ механигы
7. Баранов Дмитрий Геннадьевич – Куралово авыл җирлеге депутаты, ВРЭС «Буа электр челтәрләре» челтәр компаниясе АҖ мастеры
8. Попов Сергей Александрович – Куралово авыл җирлеге депутаты, «Вертикаль» ЯАҖ машина йөртүчесе
9. Прокопьев Альберт Иванович – Куралово авыл җирлеге депутаты, «Таткрахмалпатока» АҖ генераль директоры
10. Гайнутдинова Татьяна Николаевна- Рус Борнаш авылында яшәүче, староста
11. Маслов Георгий Георгиевич- Куралово авыл җирлеге депутаты, МБОУ «Куралово урта мәктәбе» директоры
12. Ильичев Александр Александрович- Куралово авыл җирлеге депутаты, МТФ мөдире.
13. Агеева Лидия Петровна- Куралово авыл җирлеге ветераннар оешмасы рәисе

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Куралово авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе: Т.Ю.Тимиряева**

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Куралово торак пунктлары территорияләрен санитар чистарту буенча чаралар ПЛАНЫ**

| № | Чараның исеме | Үткәрү датасы | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1 | «Куралово һәм Рус Бурнашы авылларын төзекләндерү буенча эш планын раслау» төзекләндерү буенча комиссия утырышы | Апрель | Авыл җирлеге Башлыгы. |
| 2 | Куралово һәм Р. Бурнашы авылларында «икеайлык» кысаларында территорияне санитар чистарту буенча гражданнар җыеннарын үткәрү | Апрель-Май | Авыл җирлеге Башлыгы, авыл җирлеге депутатлары, участок вәкиле |
| 3 | Юл буе полосаларын һәм кюветларны чүп чардан чистарту буенча өмәләр оештыру | Май | Авыл җирлеге Башлыгы |
| 4 | Бердәм санитар көн билгеләргә- чәршәмбе | Җәй буе | Авыл җирлеге Башлыгы |
| 5 | Йорт яны территорияләре буенча рейдлар үткәрү | Май | Авыл җирлеге Башлыгы, авыл җирлеге депутатлары |
| 6 | «Чәчәкләр белән җир елмая», игелекле эшләр акциясе. Паркта чәчәкләр утырту. | Май | Авыл мәдәният йорты |
| 7 | «Урманга дус булып кер», әңгәмә-урманда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында уйлану | Апрель | Китапханә |
| 8 | «Безнең бакчасында маҗаралар» - экологик укулар | Май | Китапханә |
| 9 | Чиста авыллардан яшел планетага», авылны төзекләндерү акциясе | Апрель | Авыл мәдәният йорты |
| 10 | Зират чистарту өмәсе | Май | Авыл җирлеге Башлыгы, авыл җирлеге депутатлары |
| 11 | Гражданнарның хисап җыенында йомгак ясап, «Йорт яны территориясен үрнәк тоту» | Май-Сентябрь | Авыл җирлеге Башлыгы, җәмәгатьчелек |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | конкурсы игълан итәргә. | | советы |
| 12 | «Зыбочка» чишмәсен төзекләндерү | Май | Авыл җирлеге Башлыгы, мәктәп укучылары |
| 13 | Баганаларны агарту | Апрель- май | Авыл җирлеге Башлыгы |
| 14 | Учреждениеләр тирәсен җыештыру. | Апрель | Авыл җирлеге Башлыгы |
| 15 | Гомумавыл өмәләре үткәрү | Апрель-Май | Авыл җирлеге Башлыгы, авыл халкы |

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Куралово авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе:** **Т.Ю.Тимиряева**